**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

2018 елның 14 декабре                                                                 36№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 мартындагы «Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлегендә җәмәгать тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында» 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 марты 6 номерлы карары белән расланган Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлегендә җәмәгать тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибенә ( алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 4 статьясындагы беренче абзацында «муниципаль берәмлек башлыгы» сүзләрен «муниципаль берәмлек башлыгы яисә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле администрация башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;
- 2 бүлекнең 5 статьясындагы икенче абзацында «Муниципаль берәмлек башлыгы» сүзләрен «Муниципаль берәмлек башлыгы яисә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле администрация башлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендында урнаштырырга.

Совет рәисе
Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы                                        М.Г. Исхаков

(Печать: Совет Старочелнинского сельского поселения, р 06-583/14)